ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АЛЕКСЕЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

АЛЕКСЕЕВСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

20.05.2019 Алексеевск ш.т.б. № 211

**Кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына файдалануга тапшыру өчен билгеләнгән Алексеевск муниципаль районы милкендә булган муниципаль мөлкәт исемлеген формалаштыру, алып бару һәм мәҗбүри бастырып чыгару кагыйдәләрен раслау турында**

Алексеевск муниципаль районы территориясендә кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына шулай ук кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына ярдәм инфраструктурасын төзүче оешмаларга мөлкәти ярдәм күрсәтү максатларында, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131- ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясына, «Россия Федерациясендә кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү турында» 2007 елның 24 июлендәге 209-ФЗ номерлы Федераль законның 18 статьясына таянып

**карар бирәм:**

1. Муниципаль мөлкәт, шул исәптән кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына шул исәптән кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына ярдәм инфраструктурасын төзүче оешмаларга файдалануга тапшыру өчен билгеләнгән өченче затларның хокукларыннан ирекле (хуҗалык алып бару, оператив идарә итү хокукыннан, шулай ук кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларының мөлкәти хокукларыннан тыш) һәм Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы милкендә булган җир кишәрлекләре (шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару, яшелчәчелек, бакчачылык, шәхси торак төзелеше өчен билгеләнгән җир кишәрлекләреннән тыш) исемлеген формалаштыру, алып бару һәм бастырып чыгару тәртибен расларга (кушымта).
2. Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Башкарма комитетының «Алексеевск муниципаль районы милкендә булган, өченче затлар хокукларыннан (кече һәм урта эшкуарлык субъектларының мөлкәт хокукларыннан тыш) ирекле муниципаль мөлкәт исемлеген формалаштыру,

алып бару һәм мәҗбүри бастырып чыгару Кагыйдәләрен раслау турында» 2017 елның 27 февралендәге 82 номерлы карары үз көчен югалткан дип танырга.

3. Әлеге карарны Алексеевск муниципаль районының рәсми сайтында һәм хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Алексеевск муниципаль районының Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы рәисе Гайсин М.Р. йөкләргә.

**Башкарма комитет җитәкчесе** **Н.К. Кадыйров**

Татарстан Республикасы
Алексеевск муниципаль районы
Башкарма комитетының
20.05.2019 № 211
карарына кушымта

**Муниципаль мөлкәт, шул исәптән кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына шул исәптән кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына ярдәм инфраструктурасын төзүче оешмаларга файдалануга тапшыру өчен билгеләнгән өченче затларның хокукларыннан ирекле (хуҗалык алып бару, оператив идарә итү хокукыннан, шулай ук кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларының мөлкәти хокукларыннан тыш) һәм Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы милкендә булган җир кишәрлекләре (шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару, яшелчәчелек, бакчачылык, шәхси торак төзелеше өчен билгеләнгән җир кишәрлекләреннән тыш) исемлеген формалаштыру, алып бару һәм мәҗбүри бастырып чыгару тәртибе**

1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге тәртип озак сроклы нигездә, шул исәптән ташламалы шартларда муниципаль мөлкәт, шул исәптән кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына шулай ук кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына ярдәм инфраструктурасын төзүче оешмаларга файдалануга тапшыру өчен билгеләнгән өченче затларның хокукларыннан ирекле (хуҗалык алып бару, оператив идарә итү хокукыннан, шулай ук кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларының мөлкәти хокукларыннан тыш) һәм Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы милкендә булган җир кишәрлекләре (шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару, яшелчәчелек, бакчачылык, шәхси торак төзелеше өчен билгеләнгән җир кишәрлекләреннән тыш) исемлеген формалаштыру, алып бару һәм мәҗбүри бастырып чыгару ысулны билгели (алга таба - Исемлек)

1.2. Исемлекне формалаштыру һәм раслау Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Башкарма комитеты тарафыннан гамәлгә ашырыла.

1.3. Мөлкәтне кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына бушлай күчерү, «Дәүләт һәм муниципаль милектә булган һәм арендалана торган кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары тарафыннан күчемсез милекне читләштерү үзенчәлекләре турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2008 елның 22 июлендәге 159-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә булган очраклардан һәм Россия Федерациясе Җир кодексының 39.3 статьясындагы 2 пунктының 6, 8 һәм 9 пунктчаларында күрсәтелгән очраклардан тыш исемлеккә кертелгән муниципаль милек шәхси милеккә бирелергә тиеш түгел.

1.4. «Дәүләт һәм муниципаль милектә булган һәм арендалана торган

кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары тарафыннан күчемсез милекне читләштерү үзенчәлекләре турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2008 елның 22 июлендәге 159-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә һәм Россия Федерациясе Җир кодексының 39.3 статьясындагы 2 пунктының 6, 8 һәм 9 пунктчаларында күрсәтелгән очраклардан тыш муниципаль милекне кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары милкенә түләүсез күчерүдән тыш, исемлеккә кертелгән муниципаль мөлкәтне сату тыела. Мондый мөлкәтне кече һәм урта эшмәкәрек субъектларына, кече һәм урта эшмәкәрек субъектларына ярдәм инфраструктурасын барлыкка китерүче оешмаларга субарендага бирүдән тыш, әгәр дә субарендада «Конкуренцияне яклау турында» 2006 елның 26 июлендәге 135-ФЗ номерлы Федераль законның 17.1 статьясындагы 1 өлешенең 14 пунктында каралган мөлкәт бирелә икән, күрсәтелгән мөлкәткә карата алардан файдалану хокукын яңадан алу, аларны залогка тапшыру һәм мондый мөлкәттән файдалану хокукын теләсә кайсы хуҗалык эшчәнлегенең теләсә кайсы башка субъектларының устав капиталына тапшыру, мондый мөлкәтне арендалау килешүләре буенча хокукларны һәм бурычларны өченче затларга тапшыру (яңадан рәсмиләштерү) тыела.

1.5. Муниципаль милекнең расланган исемлеге, шулай ук мондый исемлекләргә кертелгән үзгәрешләр турында белешмәләр «Россия Федерациясендә кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү турында» 2007 елның 24 июлендәге 209-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясындагы 5 өлеше нигезендә, мониторинг үткәрү максатларында, кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү корпорациясенә тапшырылырга тиеш. Күрсәтелгән мәгълүматларның составы, аларны тәкъдим итү вакыты, тәртибе һәм формасы эшмәкәрлек эшчәнлеген, шул исәптән урта һәм кече бизнесны үстерү өлкәсендә дәүләт сәясәтен эшләү һәм норматив-хокукый җайга салу функцияләрен гамәлгә ашыручы федераль башкарма хакимият органы тарафыннан билгеләнә.

## 2. Исемлекне формалаштыру тәртибе

2.1. Исемлек әлеге Тәртипнең 2.2 пунктында күрсәтелгән өченче затларның хокукларыннан (хуҗалык алып бару, оператив идарә итү хокукыннан, шулай ук кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларының мөлкәти хокукларыннан тыш) ирекле булган муниципаль мөлкәт санынннан төзелә.

2.2. Исемлеккә биналар (корылмалар), өченче затлар хокукларыннан ирекле (кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларының милек хокукларыннан тыш) торак булмаган йортлар кертелә, шулай ук корылмалар, җиһазлар, махсуслаштырылган транспорт чаралары (үзйөрешле машиналар) кертелергә мөмкин.

2.3. Күрсәтелгән исемлеккә, кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына арендага бирелгән җир кишәрлекләреннән тыш, Россия Федерациясе Җир кодексының 39.11 статьясындагы 1 - 10, 13 - 15, 18 һәм 19 пунктчаларында каралган җир кишәрлекләре кертелми.

2.4. Муниципаль унитар предприятиегә хуҗалык алып бару яисә

оператив идарә итү хокукында, муниципаль учреждениегә оператив идарә хокукында күрсәтелгән предприятиеләр яки учреждениеләр һәм җирле үзидарә органы тәкъдиме буенча, тиешле мөлкәт белән алыш-бирешне килешергә вәкаләтле орган тәкъдиме белән беркетелгән муниципаль милек кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына һәм кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына ярдәм инфраструктурасын төзүче оешмаларга мондый милекне биләү һәм (яки) файдалануга бирү максатларында исемлеккә кертелергә мөмкин.

2.5. Исемлектән мөлкәтне төшереп калдыру түбәндәге очракларда башкарыла:

- кулланыштан алу;
- мөлкәтне югалту;
- мөлкәтнең күләм һәм сыйфат характеристикаларын үзгәртү нәтиҗәдә әлеге мөлкәт үзенең билгеләнеше буенча файдалану өчен яраксыз булуы;
- мөлкәтне билгеләнгән тәртиптә Федераль милеккә, Татарстан Республикасы милкенә, Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы муниципаль берәмлеге составына керүче җирлекләр милкенә тапшыру;
- әлеге мөлкәтнең муниципаль ихтыяҗлар өчен кирәк булуы;
- муниципаль милекне арендалау шартнамәсен төзү хокукына өч тапкыр аукцион (бәйгеләр) үткәрү нәтиҗәләре буенча гамәлдәге законнар нигезендә аренда килешүләре төзү. Әлеге милекне киләчәктә ничек файдалану турында идарә карары кабул ителә.

2.6. Мөлкәт исемлеге Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Башкарма комитеты карары белән раслана.

## 3. Исемлекне алып бару тәртибе

3.1. Исемлекне алып бару Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы тарафыннан электрон рәвештә алып барыла.

3.2. Исемлек түбәндәге мәгълүматларны үз эченә алган реестрдан гыйбарәт:

- тәртип буенча номер;
- милекнең реестр номеры;
- муниципаль милекнең исеме;
- мөлкәтнең идентификацион мәгълүматлары (кадастр номеры һәм башкалар);
- милек характеристикалары (мәйданы, катлар саны, озынлыгы һәм башкалар);
- муниципаль күчемсез милекнең урнашу урыны;
- милекнең максатчан билгеләнеше (әгәр милек төрле максатчан билгеләнеше буенча кулланылырга мөмкин булса, исемлектә аны куллануның мөмкин булган барлык очраклары да күрсәтелә);
- күчемсез милеккә карата чикләүләр (кыенлыклар) турында мәгълүмат.

4. Исемлекне бастырып чыгару тәртибе

4.1. Исемлек һәм аңа кертелә торган үзгәрешләр исемлекне раслау яки аңа үзгәрешләр кертү көненнән соң 10 эш көненнән дә соңга калмыйча Алексеевск муниципаль районының рәсми сайтында мәҗбүри басылып чыгарга һәм урнаштырырга тиеш.

**Башкарма комитет эшләре белән идарә итүче Г.А. Юсупова**